УДК 908

# ИЖ-БУБИ МӘДРӘСӘСЕНЕҢ ТАУ ЯГЫ МӘГАРИФЕ ҮСЕШЕНӘ ЙОГЫНТЫСЫ: АКЪЕГЕТ МӘДРӘСӘСЕ ТАРИХЫННАН СӘХИФӘЛӘР

***Э.К. Сәлахова***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*ilsalah@mail.ru*

XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар буржуазия вәкилләре ярдәме белән татарлар күпләп яшәгән һәр төбәктә мәдәният үзәге булган җәдиди уку йортлары ачыла. Шундый уку йортларының күбесе авыл җирлегендә эшләгән, һәм алар аерым төбәкнең мәгариф үзәге булып торганнар. Бу мәдрәсә җитәкчеләре, остазлары тырышлыгы нигезендә татар-мөселман дөньясында танылганнар һәм бәяләнгәннәр. Атаклы мәдрәсәләрнең эшчәнлеге һәм тәҗрибәсе җәдиди белем бирүне киңрәк даирәгә тарату мөмкинлегенә өмет уяткан. Уникаль дип аталырга хакы булган шундый мәдрәсәләрнең берсе – Вятка губернасы Сарапул өязе Иж-Бубый авылы мәдрәсәсе. Бу авыл мәдрәсәсенең тарихы бертуган Нигъмәтуллиннар белән бәйле, аларның тәҗрибәсе, бу мәдрәсәдә үскән кадрлар татарларда гына түгел, ә башка төрки халыклар арасында да мәгариф үсешенә зур өлеш керткән. Бу хезмәтнең максаты: Иж-Буби мәдрәсәсенең Казан губернасы Тау ягы мәгарифе үсешенә йогынтысын күрсәтү. Казан губернасы Чар өязе Акъегет авылы мәдрәсәсе тарихы нигезендә, кайда урнашуларына бәйле булмастан, татар мәдрәсәләренең бер-берсе белән аралашуы һәм хезмәттәшлеге күрсәтелә. Хезмәт әлеге атаклы мәдрәсәләрнең тарихы хакында XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар мәгарифе бердәмлеге кысалары эчендә фикер йөртеп бәяләүгә юнәлтелгән. Бу аның яңалыгын да билгели. Мәсьәләгә карата кулланылган мондый алым Иж-Буби тарихында да, шулай ук Акъегет мәдрәсәсе тарихында да аз билгеле булган сәхифәләрне ачыкларга мөмкинлек бирде. Акъегет мәдрәсәсендә укыткан мөгаллимнәрнең зур күпчелеген Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләр тәшкил иткәнлеге ачыкланды, димәк, Тау ягында җәдитчелекне башлап кертүчеләр, үстерүчеләр дә алар икәнлеге аңлашыла. Бу уку йортлары эшчәнлеге мисалында XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар авылларында югары мәдәният үсеше күрсәтелә.

**Ачкыч сүзләр:** мәгариф, мәдрәсә, җәдидчелек, татар халкы тарихы, татар хәйриячелеге.

Казан ханлыгы яуланып алынгач, татарның рухи тормышы авылларга күчә. Авыл төшенчәсенең һәрвакытта үз эчтәлеге булган. Хәзерге вакытта авыл бертөрле булса, совет чорында ул икенчерәк була, ә инкыйлабка кадәрге чор авылы ул бөтенләй башка. Җир эшкәртү, һөнәрчелек белән шөгыльләнүче кешеләр яшәгән татар авылы XIX йөз ахыры – XX йөз башында мәгариф һәм мәдәният үзәгенә дә әйләнә. Кайбер авыллар бу җәһәттә шактый аерылып та торганнар.

Уку-укытуга, халыкның рухи тормышы үсешенә, әлбәттә, авылның мөхтәрәм, табигатьтән талантлы кешеләре, имамнар рух бирә. Алдынгы карашлы, белемле һәм шул ук вакытта мөлкәтле кешесе булган авылларда мәчетләр дә салынган, мәчет каршында мәктәбе дә эшләгән, кайбер авыллардагы уку йортлары татар-мөселман дөньясының танылган мәдрәсә дәрәҗәсенә дә үсеп җиткән.

Татар халкының мәгарифе туу һәм үсеш тарихын, аның халык буларак дәрәҗәсен күрсәтү өчен татарлардагы гаять уникаль хәйриячелек тарихы белән берлектә тәкъдим итү кирәктер. Урыс уку йортларыннан аермалы буларак, татар мәктәп-мәдрәсәләре беркайчан да хөкүмәт хисабына яшәмәгән. Аларның кайсының гына тарихын алсак та, аның нигезләнүе, яшәеше я мәхәллә халкы, я аерым хәйрияче исеме белән бәйле. Мәдрәсәләрнең күпчелеге әлбәттә бай катлам яшәгән якларда ачылган, мәдрәсәне яшәтү өчен ярдәм итүче химаяче булу кирәк. Шәһәрләрдә сәүдә итеп мал туплаган байлар, гадәттә, туган җирләрендә мәдрәсә ачарга һәм аны тотарга тырышканнар. Авыл җирлегендәге атаклы мәдрәсәләрнең күпчелеге Казан артына туры килә: Кышкар, Курса, Мәтәскә, Түнтәр, Мамадыш ягындагы Сатыш мәдрәсәләре тирә-якка данлыклы булалар. Бу уку йортларының кайберләре статуслары буенча мәктәп булсалар да, халык үз уку йортларын мәдрәсә дип атап йөрткән, хезмәт куючы остазларын зурлаган, мондый уку йортларына ерак җирләрдән үк килү шәкерт өчен мәртәбә саналган. Татар авылларының зур күпчелегендә уку йортлары булган, әмма зур уку йортлары – мәдрәсәләр тоту һәрбер авыл, мәхәлләнең хәленнән килмәгән. Кызганычка каршы, авылларда халыкның үз көче белән салынган күп кенә мәдрәсәләр хакында безнең мәгълүматыбыз юк. Татарларның мәркәз үзәкләрендә Казан, Оренбург, Уфада эшләгән атаклы уку йортлары – мәдрәсәләр хакында фәнни әдәбияттан мәгълүмат алырга мөмкин. Авыл җирлегендә эшләгән иң атаклы уку йортларының берсе, әлбәттә Иж-Бубый авылы мәдрәсәсе (Бертуган Бубыйлар: 14–90). Әһәмияте ягыннан Иж-Буби мәдрәсәсеннән калышмаган, Тау ягының мәгариф үзәге булган атаклы җәдид мәдрәсәсе Чар өязе Акъегет авылы (хәзерге Яшел Үзән районы) мәдрәсәсе. Бу ике уку йорты да оешкан дәвердә гади генә авыл мәдрәсәсе булып эшләрен башлый, аннан җәдиди уку йорты югарылыгына күтәрелеп, шул чорның зыялыларын тәрбияләүдә эш алып бара. Бу ике уку йортының да дәрәҗәсе зур була, аларда ислам динен кабул иткән башка халык вәкилләреннән дә шәкертләр булуы билгеле. Территориаль яктан бу ике мәдрәсә бер-

берсеннән ерак урнашкан булсалар да, алар арасындагы бәйләнеш тыгыз булганы күренә.

Чар өязе Акъегет авылының XIX гасырның 70 нче елларында ачылган мәдрәсәсе Тау ягының мәгариф үзәге була. Бу уку йорты Себер ягында сату итеп мал туплаган бертуган Шәфигуллиннар һәм Архангельск шәһәрендә сәүдә иткән Акъегет авылы кешесе Закир Ишмәмәтев акчасына булдырыла һәм алар ярдәме белән яши (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 6–8). 300 шәкерткә белем биргән зур мәгариф учагы бу төбәкнең белем һәм мәдәни үзәге генә булып калмыйча, XX йөз башында барган үзгәрешләрдә яңа фикер туу урыны да була. Акъегет мәдрәсәсе, ул мәдрәсәне тотучы Заһидулла Шәфигуллин тирә-як авыллары тормышына да зур тәэсир ясый. Аның акчасына мәчетләр салына, мәчетләр каршында мәктәпләр ачыла.

Заһидулла Шәфигуллин сәүдәгәр, эшмәкәр генә түгел, ә җәдидче буларак бик ихтирамлы һәм танылган кеше була. Аны И. Гаспринский, Г. Баруди, Г. Апанаев кебек атаклы кешеләр таныган, хөрмәтләгән. «Аның тарафыннан салынган мәктәпләрнең һәммәсендә ысулы җәдидә берлә тәгълим ителә. “Тәрҗеман” мөхәррире Исмәгыйль Гаспринский җәнаблары халыкны ысулы саутиягә өндәгән вакытта иң башлап кабул итүче Заһидулла хаҗи булган», дип яза XX йөз матбугаты (Заһидулла Шәфигуллин: 6–7). Жандармерия документларында аның хакында «он был Галеевского и Иж-Бобьинского закала» (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 6а – 8), дип язылса. Әлбәттә, бу сүзләр жандармерия документларында негатив эчтәлектә бирелсә дә, аларның болай бәяләве мәдрәсәне җитәкләгән кешенең шул заманның прогрессив фикерле кеше булганлыгын күрсәтә.

Акъегет мәдрәсәсе башлангыч чорында башка дини уку йортлардан берни белән дә аерылып тормаган. 1895 елда бина киңәйтелә, чөнки мәдрәсәдә укучылар саны арта, XX йөз башында аларның 300 кешегә җитә. Шәкертләрнең 70 ләбе ерактан килеп укучылар була. Биредә Чистай, Буа, Минзәлә өязе авылларыннан килгән балалар һәм яшьүсмерләр укый. Хәтта ки, бер шәкертнең Владивостоктан да булуы мәгълүм. Читтән килгән балалар Шәфигуллиннар исәбенә яшәгәннәр дә, алар исәбенә тукланганнар да, белем бирү дә тулысынча алар исәбеннән була. Шәфигуллин бу гамәлләрен бик үк сиздерергә теләмәгән, хәтта дәүләт чиновниклары кызыксынганда ул шәкертләрне үз исәбенә тотуын инкарь итә торган була.

Мәдрәсә утары тулы бер комплекстан торган, аның янында укытучылар яши торган ике катлы йорт, шәкертләр юыну өчен мунча, ашханә була, ашханәдә һәрвакыт чәй кайнап торган, шәкертләр теләгән вакытта кереп чәй эчә алганнар. Мәдрәсә комплексының янында алма бакчасы үскән.

1913 ел мәгълүматлары буенча бу мәдрәсәдә 9–18 яшьлек шәкертләр белем алган, бу вакытта аларның саны алдагы елларга караганда 2 тапкыр азрак – бары тик 114 шәкерт укыганлыгы күренә. Шәкертләрнең ике тапкыр кимүе ниндидер сәяси яисә һич кенә дә мәгариф эшләрендәге

кимчелек белән бәйле түгел. Бары тик 1903–1913 еллар арасында Тау ягында берничә мәдрәсә ачыла, шул сәбәпле шәкертләр үзләренә якынрак мәдрәсәләрдә укуларын дәвам иткәннәр. Шәфигуллин химаячелеге нигезендә салынган шундый мәдрәсә 1913 елның сентябрь аенда Чүти авылында эшли башлый, Тәтеш өязенең Чирмешән авылында да Садыйк Сабитов акчасына мәдрәсә ачыла һәм дә атаклы мәдрәсәләрнең берсе – Буа өязе Норлат авылында эшләп килә.

Заһидулла Шәфигуллин – җәдитче, ул милләт үсешен, аның киләчәген кайгыртучы милли интеллигенция вәкиле. Ул үзе укый-яза белмәсә дә, белем кирәклеген аңлаган, аңлап кына калмыйча, татар халкының киләсе буыннарын белемле итүгә бар гомерен багышлаган фидакарь бер зат. Документларда: «Шафигуллин – убежденный сторонник распространения образования в мусульманской среде. При разговорах с должностными лицами Шафигуллин высказывает, что татары необразованны, некультурны и экономически оскудели и что только образование может сделать татар культурными и поднять экономический их уровень» (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 1–2), диелә.

Әлбәттә аның бу гаять киң кырлы эшчәнлеге барлык яктан да ризасызлык тудыра. Беренчедән, тирә-як авылларның муллалары җәдиди укуга шикләнеп, хәтта куркып карaулары сәбәпле, әле шуның өстенә рус класслары ачылу да, традицион карашлы халыкны да, руханиларны да шик-шөбһәгә сала. Икенче яктан, аның мондый кыю, батыр эшчәнлегеннән власть вәкилләре курка. Аларны бу якларда җирле халыкның татарлар кебек үк төп өлешен тәшкил иткән, татарлар белән күп гасырлар бертугандай яшәгән, хәтта ки татарча сөйләшкән чуашларның мөселманлыкка чыгу, татарлашу куркынычы булуы борчый. Эше, гамәле белән көчле Шәфигуллиннар тарафыннан үз мөмкинлекләре, үз капиталы белән моны башкару куркынычы, әлбәттә, зур була.

1897 елдан башлап Акъегет мәдрәсәсе җәдиди уку программасы белән эшли башлый, бу адымга баруга да җәдиди укуга күчеп барган уку йортларының, шул исәптән Иж-Буби мәдрәсәсенең дә, уңышлы тәҗрибәсе этәргеч ясаган. Акъегет мәдрәсәсе 1907 елда Казан укытучылары икенче корылтаенда эшләгән программа буенча, аерым алганда, Апанай мәдрәсәсе уку программасына якын программа белән укыта. Мәдрәсә 5 бүлектән һәм 2 сыйныфтан торган. Беренче класста курсны узу вакыты 3 ел, икенче класста уку курсы 7–8 ел дәвам иткән. Биредә гакаид, тәҗвид, ана теле, арифметика һәм башка предметлар укытылган. Укыту татар телендә алып барылган. Жандарм документында «ул, күп игътибарны халык мәгарифенә юнәлтә. Муллалар һәм мөгаллимнәр укытуда татар теленә һәм дөньяви предметларга күбрәк игътибар бирсеннәр, дип тырыша», диелә (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 6а – 8).

Мәдрәсәдәге ысулы саутия методы белән укытуның нәтиҗәлелеген, файдасын, укыту дәрәҗәсен күрсәтү максаты белән дә ел саен ачык имтиханнар оештырылган. Имтиханнарга тирә-як муллалары, Чар һәм

күрше өязләрдән мөхтәрәм кешеләр чакырылган. Бу ачык имтиханнарның башка төбәкләрдәге уку йортларының да җәдиди укыту ысулына күчәргә дәлил дә, этәргеч тә була.

1912 елда мәдрәсә каршында рус классы ачыла, үз хисабына әлеге классны ачуны сорап Заһидулла Шәфигуллин чиновникларга 1908 елда ук мөрәҗәгать итә. Рус телен өйрәнү җирле халык арасында шактый популярлаша, теләүчеләр артканнан-арта бара. Бу класста 84 кеше белем алган өстенә, укырга килергә теләүчеләр тагын да 40 кеше була. Мәдрәсә берьюлы шулкадәр кешене сыйдыра алмый, шуңа да рус теле укытучысы Әхмәди Гордеев Шәфигуллин исәбенә рус телен укыту өчен кичке курслар ачарга рөхсәт бирүне үтенә. Әлбәттә инде, ризалык бирелми. Чиновник татарларга рус теле укыту белән аларның дөньяга чыгу, аралашу даирәсенең киңәюеннән шүрли.

З. Шәфигуллин авылда кызлар укыту эшенә дә нигез сала. Иң беренче итеп кызлар мәктәбен үз өендә, үз исәбенә ачып җибәрә. 1913 елга кадәр кияүгә чыгып, авылдан киткәнчегә кадәр кызларны укыту эшенең башында озак еллар буе үз кызы Әсма тора (ТР ДА. Ф. 1. Э. 5482: 253а – 255а).

Кызлар мәктәбенең дә үз бинасы барлыкка килә. Мәктәп югары очта тау башына салынган ике бер катлы бинадан торган. 1913 елга караган волость идарәсе документлары буенча күрсәтелгән вакытка монда 130 кыз белем алган, ә Шәфигуллиннар мәгълүматы буенча бу вакытта укучы кызларның саны күбрәк – 140 кыз була. Кызлар мәктәбендә дә рус классы эшләгән: 1912 елдан башлап монда рус теленнән М. Салихова, ә татар классларында 1913 елдан башлап М. Камалова белем биргән (ТР ДА. Ф. 160. Э. 1463: 6а – 8б).

Мәдрәсәне көчле уку йорты итүдә, һичшиксез, аның мөгаллимнәренең хезмәте, аларның белеме, тырышлыгы тора. Бу уку йортының мөгаллимнәр составы чын мәгънәсендә көчле һәм сайлап тупланган була. Читтән килгән мөгаллимнәргә яшәү, эшләү өчен Заһидулла бай бар мөмкинлекне дә тудырырга тырыша, мөгаллимәләр өчен аерым йортлар төзетә. Укыту сыйфатының югарылыгын күрсәтә торган тагын бер факт – мөгәллимнәрнең зур күпчелеге Иж-Бубины тәмамлап чыккан шәкертләр, кызлар була. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар белән тыгыз дустанә мөнәсәбәттә торган Заһидулла бай аларның юлын хуплап, эшләренә терәк булып та тора, алар укыткан методиканы үз мәктәбенә дә ала, аннан укытучылар да китертә.

Заһидулла Шәфигуллинның кызы Әсма Акъегет авылындагы кызлар мәктәбе белән 1913 елга кадәр җитәкчелек итә, әмма ул аның рәсми җитәкчесе булып саналмаса да, бу төбәктәге кызларны белемле итүгә аның бәһасез зур хезмәте керә. Аннан ул Иж-Бубый кешесе – дәреслекләр авторы, танылган педагог Якуб Хәлили (1877–1938) белән никахлашып, Казанга күчеп китә. Яры итеп Иж-Бубый авылы кешесен, атаклы Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертне сайлау да бу ике авылның эшлекле

бәйләнеше булганлыгын күрсәтүче бер дәлил итеп санап була. Якуб Хәлили төрле җирләрдә мөгаллимлек итү белән, берара Акъегет авылы мәдрәсәсендә дә укыта. Фикере, киләчәккә тоткан юлы белән бер-берсенә охшаш, бер-берсен аңлый торган бу ике кеше мәгърифәт юлында бергә китеп, тагын да яңа үрләр, яңа юнәлешләр үзләштерә башлыйлар. 1913 елның 16 сентябрендә Я. Хәлили «Сөембикә» журналы чыгарырга рөхсәт ала (Махмутова: 44–45). Бу игелекле эшне тормышка ашыруга Заһидулла кызы Әсманың бирнәсе кулланыла. Журналның беренче елларында, мәкаләләргә кытлык булганда, алар икәүләп язганнар, 1913–1918 еллар аралыгында барлыгы 115 санны дөньяга чыгаруга ирешәләр (Гимазова).

Буби белән Акъегетнең мәгънәви якынлыгын күрсәтүче тагын мөһим бер факт – Акъегет авылы мәдрәсәсенең мөгаллимнәр составының күпчелек өлешен Бубый авылы мәдрәсәсен тәмамлаучылар тәшкил иткән. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларның яңача укыту методикасы, аларның киләчәккә карашы, шулай ук аларның иҗтимагый позициясен хуплап кабул иткән Заһидулла Шәфигуллин бу мәдрәсә белән эшлекле бәйләнешләр булдыра, Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаган укытучыларны үз мәдрәсәсенә китерү, аларга тиешле эш һәм яшәү шартлары булдырырга матди мөмкинлеген кызганмый. Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлап чыккан яшьләрнең тулы исемлеге һәм аларның алга таба кайларда хезмәт иткәнлеге турында төгәл генә мәгълүматны күрсәтә алмасак та, аерым уку йортлары эшчәнлеге мисалында Буби шәкертләре булган яшьләрнең үзләренең дә мөгаллимлек иткәннәре, алган белемнәрен үзләреннән соң килгән буынга җиткерүләре күренә. Шундыйлардан, Иж-Буби мәдрәсәсен тәмам итеп Акъегет авылына мөгаллимлек итәргә килгән Зәйтүнә Фәхри-Юлмәтева. Бу туташ тумышы белән Самара губернасы Бөгелмә өязенә карый торган Зәй-Каратай авылында имам гаиләсендә дөньяга килгән. Әтисе Чистайда Камаловлар мәдрәсәсен тәмамлаган кеше була, кызына да заманча җәдиди белем бирүгә омтылган алдынгы карашлы имам, кызын 1906 елда укырга Чистайга алып килә, Зәйтүнәне яшәр өчен Мортаза Ваһапов өендә калдыра. Зәйтүнә Фәхри соңрак хатын-кыз мәгарифе, татар журналистикасында танылу алган М. Ваһаповның кызы – билгеле ханым Фатыйма-Фәридәдә белем ала. Зәйтүнә алга таба белем алырга Иж-Буби мәдрәсәсенә килә һәм бу уку йортын тәмамлавы белән Акъегет авылы кызларын укытуга юнәлә, биредә ул 1909–1911 еллар аралыгында хезмәт куя. Зәйтүнә Фәхри-Юлмәтева үз истәлекләрендә аны Заһидулла бай Шәфигуллин кызы Әсма белән бергәләп олылап каршы алуларын күрсәтә. Мөгаллимәне укытучылар өчен махсус салдырылган йортка урнаштыралар. Мөгаллим-мөгаллимәләрнең яшәүләре, ашау-эчү чыгымнарын – барысын да Заһидулла бай үзе күтәргән. Мөгаллимәнең эш хакы өчен 25 сум түләнгән, әмма мөгаллимә үз хатирәләрендә: «Моннан кала балалар биргән сәдака, хәер акчасы шактый җыела иде», – ди. Сәдакадан баш тарту тәрбиясезлек билгесе итеп кабул ителгән. Татар халкында хезмәтне бәхилләтү дигән нәрсә бар, бигрәк тә белемгә, укытучы хезмәтенә зур

ихтирамлы халык хәленнән килгән кадәр хәер акчасы биргән. Хәтта халыкта «Хәерсез алынган белем – файдасыз» дигән әйтем дә була.

Иж-Буби мәдрәсәсе ябылганчы 6 ел укытып калырга өлгергән Мәнбәгел Адылева Акъегет авылына мөгаллимә буларак чакырыла, жандармерия документларында бу мөгаллимә дин гыйлеме укытучысы буларак кына китерелгән булса да, татар сыйныфында барлык предметлар буенча да белем бирә, дигән ризасызлык күрсәтелә (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 1–2б). Ул тумышы белән Алабуга өязенә караган Салагыш (хәзерге Әгерҗе районы) авылыннан. Монда килгәнче ул Уфа губернасы Бөре өязенең Өчиле авылында эшләп тәҗрибә дә туплап өлгергән була. Әлбәттә, Иж-Буби мәдрәсәсенең татар җәмгыятендәге урыны, андагы мөгаллимнәрнең биргән белемен таратучылар властьларда курку уята, аларны һәрвакыт күзәтү кырыннан җибәрмәскә тырышалар. 1914 елда М. Адылеваның шәхесен тикшергәннән соң Уфа һәм Вятка жандармерия идарәсе тарафыннан аның сәяси ышанычсызлыгы ачыкланмады, әмма ул Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаган, димәк аны панисламист дип санап була дигән җавап алына (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 5–5б).

1900 елда Иж-Бубый авылында дөньяга килгән Мәрьям Зәйнуллина (кыз фамилиясе – Һиббәтуллина) япь-яшь кыз 1916 елда авылдашы Якуб Хәлили киңәше һәм ярдәме белән Акъегет авылына мөгаллимә булып килә. Күгәй, Айдар, Мулла иле, Сүнчәләй, Акъегет авылы кызларыннан торган 40–50 ләп укучыга белем бирә. М. Зәйнуллинаның үзе дә үсмер генә булган чордан Акъегет авылында башланган педагогик эшчәнлеге киләчәктә бу өлкәдә зур үрләргә менәргә ярдәм итә. М. Зәйнуллина мәктәп директоры булып та эшли, мәгариф бүлеген дә җитәкли, Татарстанның атказанган исеменә дә лаек була. Казан шәһәренең халык депутатларының Дәүләт советында рәис урынбасары булу да туплаган хезмәт тәҗрибәсенең нәтиҗәсе.

Акъегет авылы мәдрәсәсенең һәр укытучысы күренекле уку йортлары белем багажы белән үз хезмәт чорында шул заман өчен әзерлекле, белемле укучылар әзерләп чыгара алган. Гомумән, Акъегет авылының Тау ягының мәгариф үзәге, татар халкының мөһим бер уку йорты булып җитешүендә татар мәгърифәтчеләренең, җәдидчеләрнең фикер тәэсире бәһасез. Жандармерия документларында да З. Шәфигуллинның укый-яза белмәгән гади кешедән «милләтче», хәтта ки «милләт» төшенчәсе астында ислам динендәге халыкларның бердәмлеген танучы булып җитешүенә Иж-Бубый муллалары, Казан мулласы Галимҗан Галиев (Баруди) йогынтысы бар, диелә. Шул ук документларда З. Шәфигуллин «үтә милләтче» буларак бәяләнә (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 6–8б).].

Акъегет мәдрәсәсенең кыскача гына тарихы нигезендә XIX йөз – XX йөз башында татар мәгарифенең югарылыгын каршы якта торучы жандармерия документларындагы фраза белән күрсәтсәк, аның югарылыгы шул чорда мәгариф үсешенә, алгарышына гомерен багышлаган шәхесләрнең эшен бәяләүдә дигәннән артыгын әйтеп булмас иде.

Жандармерия документларында З. Шәфигуллин турында «в дни пресловутой свободы он мечтал иметь в своей деревне нечто вроде татарского университета» (ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183: 6–8б), диелә. Ягъни авыл җирендә, авыл мәдрәсәләрендә татарның инде университеты тудырылган була.

Гомер буе үз акчасына мәктәп, мәдрәсәне яшәткән Заһидулла Шәфигуллинның картлык көннәрендә бу уку йортларын тоту авырлаша башлый. 1910 елда 71 яшендә булган Заһидулла Шәрифуллин эшләренә ярдәм итүне үтенеп власть органнарына мөрәҗәгать итә (ТР ДА. Ф. 160. Э. 1463: 6а –8б). Шәфигуллинның властьлар белән мөнәсәбәтләре нинди генә катлаулы булуга карамастан, аның мәгариф өлкәсендә гомерлек күрсәткән хезмәте алар тарафыннан да бәяләнгән. Хәтта аның мөрәҗәгатен канәгатьләндереп кенә калмыйча, Земство собраниесе исеменнән күпьеллык фидакарь хезмәте өчен бүләкләүгә тәкъдим ителә. Хөкүмәт тарафыннан да финансланганга, бу мәдрәсә соңгы елларда инде «Русско-татарская школа» буларак эшли. Шәфигуллинның бар эшләгән хезмәте, 1917 елгы инкыйлаб килгәч, чәлпәрәмә килә. Шул кадәр хезмәт куйган 79 яшьлек хаҗи бабайны авылдан китәргә мәҗбүр итәләр, бәхетенә каршы, ул шул елны үлә һәм үз туган авылы зиратында җирләнә. Ул төзеткән мәдрәсә бинасы 1929 елга яраксыз хәлгә килә һәм ябыла. Аның күргәзмә материаллары, географик карталар Норлат мәктәбенә алына. Мәгариф үзәге булган авылда укытырга бина булмау сәбәпле, бары тик дүртеллык мәктәп кенә кала (Тимершин: 96–97).

Иж-Буби мәдрәсәсе һәм аның җитәкчелеге дә шундый ук аянычлы язмыш кичерәләр. Белем бирүнең яңа бөеклегенә чыккан, кыска вакыт аралыгында тиз темплар белән нәтиҗәле үзгәреш һәм үсеш күрсәткән мондый уку йортлары – татар җәмгыятенең йөзен билгеләүче күрсәткеч. Аларның күбесе авыл җирлегендә эшләп, төбәкне мәгариф үзәгенә әйләндерә алган. Һәр төбәктә милли мәгариф, җәдиди үзәк булу ул татарның шушы чордагы ренессансының ачык бер мисалы.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Заһидулла Шәфигуллин // Русия сәүдәсе. 1913. Б. 6–7.

ТР ДА. Ф. 1. Э. 5482 – Татарстан республикасының Дәүләт архивы (ТР ДА). 1 ф. 4 тасв. 5482 эш. 253а – 255а кгз.

ТР ДА. Ф. 1. Э. 6183 – ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 6183 эш. 6–8б. кгз.

ТР ДА. Ф. 160. Э. 1463 – ТР ДА. 160 ф. 1 тасв. 1463 эш. 6а – 8б кгз.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: тарихи-документаль җыентык. Казан: Рухият, 1999.

Гимазова Р. «Сөембикә» журналының библиографик күрсәткече (1913–1918). Казан: Отечество, 2016.

Махмутова А. Пора и нам зажечь зарю свободы! (джадидизм и женское движение). Казань: Татар. кн. изд-во, 2006.

Тимершин И. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. Казан, 2001.

**Автор турында белешмә:** Сәлахова Эльмира Кадим кызы – тарих фәннәре кандидаты, хәзерге тарих бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Россия Федерациясе); ilsalah@mail.ru

*Редакциягә керде 31.01.2022* *Кабул ителде 22.04.2022*

# ВЛИЯНИЕ МЕДРЕСЕ ИЖ-БУБИ НА РАЗВИТИЕ ПРОСВЕЩЕНИЯ В ГОРНОЙ СТОРОНЕ: СТРАНИЦЫ ИЗ ИСТОРИИ АКЗИГИТСКОГО МЕДРЕСЕ

***Э.К. Салахова***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*ilsalah@mail.ru*

В конце XIX – начале XX вв. при поддержке татарской буржуазии практически во всех регионах компактного проживания татар появились крупнейшие джадидские медресе, ставшие очагами татарской культуры. Многие из них существовали в сельской местности, становясь центрами образования определенного региона. О них благодаря руководителям или наставникам узнавали во всем татаро-мусульманском мире. Плодотворная деятельность знаменитых медресе давала надежду на широкое распространение джадитского образования среди татар. Одним из таких медресе, уникальном в своем роде, стало медресе Иж-Буби Сарапульского уезда Вятской губернии. Его история связана с деятельностью братьев Нигматуллиных, чей опыт обеспечил воспитание профессиональных кадров, послуживших просвещению не только среди татар, но и среди других народов тюркского мира. Цель данного исследования: показать влияние иж-бубинского медресе на развитие просвещения в Горной стороне Казанской губернии в целом.

На примере истории акзигитовского медресе Цивильского уезда Казанской губернии показаны взаимосвязь и сотрудничество татарских учебных заведений друг с другом, независимо от их местоположения. Новизна исследования состоит в осмыслении истории знаменитых медресе в пространстве единой образовательной системы татар в конце XIX – начале XX вв. Такой подход к проблеме позволяет раскрыть малоизвестные страницы истории как иж-бубинского, так и акзигитовского медресе. Выяснилось, что многие учителя акзигитовского медресе являлись выпускниками иж-бубинского медресе, становясь тем самым сподвижниками джадидского обучения в Горной стороне Казанской губернии.

На примере деятельности этих учебных заведений представлена Высокая культура татарского народа в сельской местности в конце XIX – начале XX вв.

**Ключевые слова:** просвещение, медресе, джадидизм, история татарского народа, благотворительность.

**Для цитирования:** Салахова Э.К. Иж-Буби мәдрәсәсенең Тау ягы мәгарифе үсешенә йогынтысы: Акъегет мәдрәсәсе тарихыннан сәхифәләр // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 1. С. 24–34. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.24-34

**Сведения об авторе:** Салахова Эльмира Кадимовна – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела новой истории, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); ilsalah@mail.ru

*Поступила 31.01.2022* *Принята к публикации 22.04.2022*

## THE INFLUENCE OF THE IZH-BUBI MADRASAH ON THE DEVELOPMENT OF EDUCATION IN THE TAW YAĞI (THE MOUNTAINOUS SIDE): PAGES FROM THE HISTORY OF THE AKZIGIT MADRASAH

***E.K. Salakhova***

*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*ilsalah@mail.ru*

In the late 19th – early 20th centuries, with the support of the Tatar bourgeoisie, the largest Jadid madrasas appeared in almost all regions of compact Tatar residence, which became centers of Tatar culture. Many educational institutions existed in rural areas, and they became centers of education in a given region. Thanks to their leader or mentors, they were recognized in the Tatar-Muslim world. The fruitful activity and experience of the famous madrasas gave hope for the widespread dissemination of Jadid education among Tatars. One of these madrasas, which can be called a unique educational institution, is the madrasah of Izh-Bobya of the Sarapulsky district of the Vyatka province. The history of this madrasah is connected with the activities of the Nigmatullin brothers, their experience, the cadres who grew up in the madrasah, served the development of education not only among the Tatars, but also other peoples of the Turkic world. The purpose of this study is to show the influence of the Izh-Bubi madrasah on the development of education in the Mountainous side of the Kazan province as a whole. Using the example of the history of the Akzigit madrasah of the Civil district of Kazan, the interrelation and cooperation of Tatar educational institutions, regardless of their location, is described. The research is aimed at understanding the history of

famous madrasas in the educational system among the Tatars of the late 19th- early 20th centuries. This is the novelty of the study. This approach to the problem made it possible to reveal little-known pages of the history of both the Izh-Bubi and Akzegit madrassa. It turned out that many teachers of the Akzegit madrasah were graduates of the Izh-Bubi madrasah, so they became the companions of Jadid education in the Mountainous side of the Kazan province.

On the example of the activities of these educational institutions, the High culture of the Tatar people in rural areas in the late 19th – early 20th centuries is presented.

**Keywords:** education, madrasah, jadidism, the history of the Tatar people, charity.

**For citation:** Salakhova E.K. Izh-Bubi mädräsäseneñ Tau yagy mägarife üseshenä yogyntysy: Ak″yeget mädräsäse tarikhynnan säkhifälär [The influence of the Izh-Bubi madrasah on the development of education in the Taw yağı (the Mountainous side): pages from the history of the Akzigit madrassa]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2022, vol. 7, no. 1, pp. 24–34. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.24-34 (In Tatar)

## REFERENCES

*Bertugan Bubylar häm Izh-Buby mädräsäce: tarikhi-dokumental jyentyk* [The Buby Brothers and the Izh-Bubi madrasah]. Kazan: Rukhiyat, 1999. (In Tatar)

Gimazova R. *«Söembikä» zhurnalynyn bibliografik кürsatkeche (1913–1918).* [Bibliographic index of the journal "Syumbike"]. Kazan: Fatherland, 2016. (In Tatar)

Makhmutova A.Kh. *Pora i nam zazhech zaryu sbobody! (dzhadidizm i zhenskoe dvizheniye)* [Jadidism and the women's movement]. Kazan: Tatar book publishing house, 2006. (In Russian)

Timershin I. *Ak"eget avyly tarikhy säkhifäläre.* [Pages of the history of the village of Akzegitovo]. Kazan, 2001. (In Tatar)

**About the author:** Elmira K. Salakhova, Cand. Sc. (History), Senior Research Fellow of the Department of Modern History, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); ilsalah@mail.ru

*Received January 31, 2022* *Accepted for publication April 22, 2022*